# Нәҗибә Ихсанова



Татарстанның һәм Рәсәйнең халык артисткасы,

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.



# Тормыш юлы

Артистка Татарстанның Азнакай районы Яңа Ташлыяр авылында 1938 нче елның 25 нче гыйнварында туа. Ире - атаклы драматург Туфан Миңнуллин белән алар Мәскәүдә Щепкин училищесының татар студиясенә укырга керү имтиханнарын тапшырганда танышканнар. Яшь Туфан сылу Нәҗибәне бер күрүдә ошата. Әмма кыз гына беренче вакытларда аңа артык өметләнергә ирек бирми. Мәскәүдә уку дәверендә дә әле артыннан йөргән Туфанны Нәҗибә, тыйнак авыл кызы буларак , бик тиз генә үзенә җибәрми.



Актриса сәхнәдә үз-үзен аямыйча хезмәт итә, дөньясын онытып образлар тудыра.



Нәҗибә ханым кебек  театр белән агуланганнар, театр җене кагылганнар гына шундый югарылыкка күтәрелә аладыр. Бөтен көчен, җанын -тәнен сәхнәгә багышлап эшләгән артистка тамашачы да җан җылысы белән җавап бирә.



Сәхнәдә 338 роль уйнаган бу ханым яшь кызлар кебек очып йөри һәм сәхнәдә шпагат ясый.



Бернинди 75 яшь күренми дә, ишетелми дә. Җылы, якты энергия йомгагы. Гаҗәп хәл, үзе бер могҗиза. Хәер, театр һәм чын сәнгатькәр шулай булырга да тиеш, ә Нәҗибә Ихсанова искерми дә, тузмый да, кешеләрдән туймый һәм туйдырмый торган шәхес. Картаю турында әйтеп тә торасы юк. Иҗатында җаваплы халык мәхәббәтенә тап булган артисттан да бәхетле артист юктыр ул.



Хәзерге вакытта да ул Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия  театрында төп рольләрне башкара



# Минем кадерлеләрем!



# Рольләре:

Гандәлиф — «Көзге ачы җилләрдә»( А.Гыйләҗев)
Маһисәрвәр — «Чаткылар» (Т.Гыйззәт)
Җомабикә — «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт)
Гөлчирә — «Әни килде» (Ш.Хөсәенов)
Розина — «Фигароның өйләнүе»( П.Бомарше)
Мәйсәрә — «Американ» (К.Тинчурин)
Нәгыймә — «Назлы кияү»( К.Тинчурин)
Хәдичә — «Зәңгәр шәл»( К.Тинчурин)
Рокыя — «Чикләвек төше»( Г.Ахунов)
Сәрдия — «Кан кардәшләр»( Ю.Әминов)
Фемида — «Ташлама утны, Прометей!»( М.Кәрим)
Тәңкәбикә — «Ай тотылган төндә»( М.Кәрим)
Миңзифа — «Кичер мине, әнкәй!» (Р.Батулла)

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!